**КАРАР**

**24 ноябрь 2021 ел** **N 3**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Күпербаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 23 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге мәсьәлә буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Күпербаш авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 100 сум тәшкил иткән 80 яшьтән өлкәнрәклардән һәм 1 төркем инвалидлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Зират коймаларын ремонтлау һәм буяу, тирә - юнен төзекләндерү (материаллар сатып алу, эшләр өчен түләү)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, җирлек башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга рөхсәт итәргә.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

Җыен беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә:

җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегендә 327 кеше, гражданнар җыенында тавыш бирүдә 173 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 131 кеше "Әйе" позициясе өчен тавыш бирде; 42 кеше "Каршы" позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Күпербаш авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Күпербаш авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 100 сум тәшкил иткән 80 яшьтән

өлкәнрәкләрдән һәм 1 төркем инвалидлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Зират коймаларын ремонтлау һәм буяу, тирә - юнен төзекләндерү (материаллар сатып алу, эшләр өчен түләү)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, җирлек башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга рөхсәт итәргә.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендында (Күпербаш авылы, Мичурин урамы, 10 йорт), интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы И.Г.Нуриев